**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

14.03.2023 264-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 17 ноябрендәге 1251-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 17 ноябрендәге 1251-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2022 елның 23 августындагы 731-п номерлы, 2022 елның 28 ноябрендәге 1138-п номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә шушы боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.И.Гобәйдуллинга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
2023 елның 14 мартындагы
264-п номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2021 елның 17 ноябрендәге 1251-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, аларның гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итү буенча административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.6.1 пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең «Торак пунктлары, территориаль зоналар, махсус сакланыла торган табигать территорияләре, территориясеннән файдалануда махсус шартлары булган зоналар чикләре урнашкан урынны график яктан тасвирлау формасын, торак пунктлары, территориаль зоналар, махсус сакланыла торган табигать территорияләре, территориясеннән файдалануда махсус шартлары булган зоналар чикләре урнашкан урынны текст белән тасвирлау формасын, торак пунктлары, территориаль зоналар, махсус сакланыла торган табигать территорияләре, территориясеннән файдалануда махсус шартлары булган зоналар чикләренең характерлы нокталары координадаталырн билгеләү төгәллегенә, торак пунктлары, территориаль зоналар, махсус сакланыла торган табигать территорияләре, территориясеннән файдалануда махсус шартлары булган зоналар чикләре турында белешмәләрне үз эченә алган электрон документ форматына карата таләпләр билгеләү турында» 2022 елның 26 июлендәге П/0290 номерлы боерыгы (алга таба – П/0292 номерлы боерык) нигезендә су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зоналары проектында билгеләнгән су белән тәэмин итү чыганагының санитар саклык зонасы чикләре турында электрон формадагы белешмәләр (чикләрнең урнашу урынына текстлы һәм график тасвирлама, координаталар системасында Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен билгеләнгән әлеге чикләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге).»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) П/0292 номерлы боерык нигезендә рәсмиләштерелгән һәм кадастр инженеры тарафыннан имзаланган XML-файл форматында электрон рәвештәге характерлы нокталарның координаталары исемлеге.»;

2.8.2 пунктта:
өченче һәм дүртенче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга.